# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлегенең хокукый, икътисадый шартларын, аны үстерү, милек рәвешләренә карамастан, инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларның хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү максатларында дәүләт ярдәменең рәвешләрен билгели.

### I. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Инвестицияләр һәм инвестиция эшчәнлеге

Инвестицияләр табыш (керем) алу яисә башка уңай нәтиҗәгә ирешү максатында инвестиция эшчәнлеге объектларына салына торган акчалардан, максатчан банк кертемнәреннән, пайлардан, акцияләрдән, башка кыйммәтле кәгазьләрдән, лицензияләрдән, машиналардан, җиһаздан, интеллектуаль кыйммәтләрдән һәм башка мөлкәттән, шул исәптән мөлкәти хокуклардан, тора.

Инвестиция эшчәнлеге - инвестицияләрне салу һәм алардан файдалану буенча гамәлдәге эшләр җыелмасы ул.

<u>2 статья.</u> Инвестиция эшчәнлеге объектлары

Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге объектлары законнар белән инвестицияләү тыелмаган, дәүләт милкендә һәм башка милектә булган төрле төрдәге мөлкәттән, интеллектуаль кыйммәтләрдән гыйбарәт.

Объектларны төзү һәм файдалану законнарда билгеләнгән экология, санитария-гигиена һәм башка нормалар таләпләренә туры килмәсә яисә гражданнарнын, юридик затларның һәм дәүләтнең закон белән яклана торган хокукларына һәм мәнфәгатьләренә зыян китерсә, аларны инвестицияләү тыела.

3 статья. Инвестиция проектлары

Инвестиция проекты - нәтиҗәлелеген техник нигезләп, оештыру-хокукый һәм икътисадый чараларны үз эченә алган, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган үрнәк методика нигезендә әзерләнгән документлар җыелмасы. Инвестиция проекты, тормышка ашырылганнан соң, табыш яисә башка уңай нәтиҗә алуны тәэмин итә.

4 статья. Инвестиция эшчәнлеге субъектлары

Инвестиция эшчәнлеге субъектлары - инвесторлар, заказчылар, эш башкаручылар, инвестиция эшчәнлеге объектларыннан файдаланучылардан һәм инвестиция эшчәнлегенең башка катнашучылары. Физик һәм юридик затлар, шул исәптән чит илләрнеке дә, дәүләтләр һәм халыкара оешмалар инвестиция эшчәнлеге субъектлары була алалар.

Инвесторлар - инвестиция эшчәнлеге субъекты буларак, инвестиция салуны гамәлгә ашыручы, аларны җитештерү чаралары яисә башка активлар алуга, төзүгә һәм яңартуга юнәлдерүчеләр.

Инвесторлар сыйфатында дәүләт мөлкәте яисә мөлкәти хокуклар белән идарә итүгә вәкаләтле органнар, физик һәм юридик затлар, шул исәптән чит илләрнеке дә, дәүләтләр һәм халыкара оешмалар була ала.

Дәүләт идарәсе органнары, инвесторлар, шулай ук инвестор (инвесторлар) тарафыннан инвестиция проектын гамәлгә ашыруга вәкаләт бирелгән башка теләсә кайсы физик һәм юридик затлар, шул исәптән чит илләрнеке дә, әгәр үзара шартнамәләрдә башкасы каралмаса, инвестиция процессында катнашучыларның эшкуарлыкка һәм башка эшчәнлекләренә тыкшынмыйча, заказчылар була алалар.

Әгәр заказчы инвестор булып тормаса, аңа үзара шартнамәдә билгеләнгән чорга һәм вәкаләтләр кысаларында законнар нигезен-

дә инвестицияләргә ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү хокукы бирелә.

Тиешле эшләр алып бару өчен лицензияләре булган физик һәм юридик затлар, шул исәптән чит илләрнеке дә, инвестиция проектларын тормышка ашыручы эш башкаручылар (подрядчылар) булырга мөмкин.

Инвесторлар, шулай ук физик һәм юридик затлар, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, чит дәүләтләр һәм халыкара оешмалар инвестиция эшчәнлеге объектларыннан файдаланучылар була алалар. Әгәр инвестиция эшчәнлеге объектыннан файдаланучы инвестор булып тормаса, инвестор белән аның арасындагы мөнәсәбәт законнарда билгеләнгән тәртиптә инвестицияләү турындагы шартнамә (контракт) белән билгеләнә.

Инвестиция эшчәнлеге субъектлары ике яисә берничә катнашучының вазыйфаларын үтәргә хокуклы.

## II. Инвестиция эшчәнлеген башкару

### 5 статья. Инвесторларның хокуклары

Барлык инвесторлар да, чит илләрнекен дә кертеп, инвестиция эшчәнлеген башкаруга бертигез хокукларга ия. Мөлкәтне һәм мөлкәти хокукларны инвестиция эшчәнлеге объектларына инвестицияләү инвесторның аерылгысыз хокукы дип танылa һәм законнар белән саклана.

Инвестор инвестицияләрнең күләмнәрен мөстәкыйль билгели һәм шартнамә нигезендә инвестицияләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле физик һәм юридик затларны үзе теләгәнчә җәлеп итә.

Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча әһәмиятле объектлар төзелгәндә, инвестор сыйфатында катнашып, дәүләт идарәсе органнары инвестицияләрне кире кайтармау һәм кире кайтару шартларында башкара.

Инвестиция эшчәнлеге объектларыннан файдаланучы булып тормаган инвестор мондый объектлардан максатчан файдаланышны тикшереп торырга һәм алардан файдаланучыларга карата законнар нигезендә төзелгән шартнамәдә (контрактта) каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга хокуклы.

Инвесторлар уртак инвестицияләүне башкару өчен шартнамә

шартларында средстволарны берләштерә алалар.

Инвестор шартнамә (контракт) нигезендә инвестицияләр һәм аларның нәтиҗәләре буенча үз хокукларын инвестиция эшчәнлегендә башка катнашучыларга тапшырырга яисә шушы максатлар әчен яңа катнашучыларны җәлеп итәргә хокуклы. Әгәр инвестор дәүләт идарәсе органнары булса, вәкаләтләрне тапшыру конкурс нигезендә башкарыла.

Инвестор законнар нигезендә инвестиция объектларын һәм нәтиҗәләрен биләргә, алардан файдаланырга һәм алар белән эш итәргә, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә реинвестицияләүне башкарырга хокуклы.

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар белән инвестицияләр кертү тыелган, чикләнгән яисә аларга турыдан-туры милек хокукы алу бирмәгән, шулай да алга таба аннан файдалануны, оператив идарә итүне яисә инвесторның бу объектлардан файдаланудан килгән керемнәрендә катнашу мөмкинлеген кире какмый торган тармаклар һәм объектлар билгеләнергә мөмкин.

Әгәр законнарга каршы килмәсә, инвестор физик затлардан һәм юридик затлардан яисә арадашчылар аша күләмен һәм номенклатурасын чикләмичә, яклар килешүендә күрсәтелгән шартлар һәм бәяләр буенча үзенә кирәкле мөлкәтне турыдан-туры сатып алырга хокуклы.

6 статья. Инвестиция эшчәнлеге субъектларының бурычлары

Инвестиция эшчәнлеге субъектлары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

законнарда билгеләнгән дәүләт стандартлары, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләренең, башка нормативларның таләпләрен;

дәүләт органнарының һәм урындагы затларның үз компетенцияләре чикләрендә бирелгән таләпләрне;

средстволарны законнар нигезендә тиешле максатта файдалануны.

Инвестиция эшчәнлегендә аерым эш төрләрен башкара торган катнашучыларның шуңа хокук бирүче лицензияләре яисә сертификатлары булырга тиеш, әлеге эшләрнең исемлеге һәм лицензияләр һәм сертификатлар бирү тәртибе законнар белән билгеләнә.

7 статья. Инвестиция эшчәнлеге субъектлары арасындагы мөнәсәбәтләр

Үзара төзелгән шартнамә (контракт) инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзләре арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салучы төп хокукый документ булып тора.

Законнарга каршы килми торган шартнамәләр (контраклар) төзү, партнерлар сайлау, йөкләмәләрне билгеләү инвестиция эшчәнлеге субъектларының хокукы булып тора. Үзара шартнамә мөнәсәбәтләрен башкарганда дәүләт органнарының һәм урындагы затларның үз вәкаләтләре кысаларыннан тыш катышулары рөхсәт ителми.

Инвестиция эшчәнлегенең төзелеп бетмәгән объектлары, инвестор (заказчы) башкарылган эшне һәм хезмәт күрсәтүләрне кабул иткәнче һәм шулар өчен түләгәнче, инвестиция процессы субъектларының милек өлеше булып тора ала. Инвестор (заказчы) проектны инвестицияләүне дәвам итүдән баш тарткан очракта, шартнамәдә башкасы каралмаса, башка катнашучыларга шуңа бәйле рәвештә барлыкка килгән чыгымнарны компенсацияләргә тиеш.

8 статья. Инвестиция эшчәнлеген финанслау чыганаклары

Инвестиция эшчәнлеге түбәндәгеләр исәбеннән башкарылырга мөмкин:

инвесторның, шул исәптән чит илнекенең дә, үз средстволары;

һәлакәтләрдән һәм табигый бәла-казалардан килгән зыянны кайтару рәвешендә иминләштерүчеләр түли торган акчалар;

бюджет акчалары;

законнар белән тыелмаган башка чыганаклар.

III бүлек. Инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салуы

9 статья. Инвестия эшчәнлеген дәүләт җайга салуы рәвешләре

Инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салуы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан үз вәкаләтләре кысаларында инвестиция сәя-

сәте үткәрү юлы белән тәэмин ителә.

Дәүләтнең инвестиция сәясәте Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеген дәүләт тикшереп торуын, экспертизасын, шулай ук аңа дәүләт ярдәмен күз алдында тота, ул түбәндәге рәвешләрдә башкарыла:

инвестицияләрне законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт чыганакларыннан финанслау;

инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларга өстенлекле салым ташламалары бирү;

инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларга дәүләт гарантияләре бирү;

республиканың аерым территорияләре, тармаклары һәм производстволары үсеше өчен кредитлар бирү.

Дәүләт ярдәменең әлеге статьяда күрсәтелгән рәвешләре Республика инвестиция программасына кертелгән максатчан программаларны һәм кайбер инвестицияләү проектларын гамәлгә ашыру өчен бирелә. Инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәме Татарстан Республикасының Республика бюджеты исәбеннән, аның чыгым өлешендәге аерым юл рәвешендә башкарыла. Дәүләт яклавы тапкан проектларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башкаручыларны (подрядчыларны) сайлап алу конкурс нигезендә үткәрелә. Конкурсларны үткәрү тәртибен һәм вакытларын Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгели.

<u>10 статья.</u> Республика инвестиция программасын төзү тәртибе

Республика инвестиция программасы - әлеге Законның 8 статьясында күрсәтелгән чыганаклардан финанслауга билгеләнгән яисә дәүләт ярдәменең башка төрләрен күз алдында тотучы максатчыл программаларның һәм инвестиция проектлары җыелмасы ул.

Республика инвестиция программасы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан алдагы бюджет елына бюджет проекты белән бергә төзелә һәм аның бер өлешен тәшкил итә.

Инвестиция проектын Республика инвестиция программасына кертү өчен аңа карата дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе булу мәҗбүри шарт булып тора, аны үткәрү тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгели.

Максатчан программаларны һәм аерым проектларны карау тәртибе, аларны сайлап алу критерийлары һәм алдагы бюджет елына Республикасы инвестиция программасына кертү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм "Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә керткәннән соң бер айдан да соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга тиеш.

Инвестицияләү тәртибе, Республика инвестиция программасын гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелә торган бюджет акчаларының максатчан һәм нәтиҗәле файдаланылышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## IV. Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлегендә катнашучы юридик затларга салым салу

### 11 статья. Салым салу

Инвесторлар, шулай ук объектны файдалануга тапшыруның норматив вакыты чыкканга кадәр инвестиция кредитлары бирелгән кредит оешмалары Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче суммалар чикләрендә инвестицияләрне гамәлгә ашыру өлешендә предприятиеләрнең мөлкәтенә һәм предприятиеләрнең, оешмаларның табышына салым түләүдән әлеге Закон нигезендә азат ителергә тиешләр.

### 12 статья. Предприятиеләр мөлкәтенә салым буенча өстенлекле ташламалар

Инвестиция эшчәнлеге объектын файдалануга тапшырганнан соң, норматив вакытны бозмыйча, беренче ел дәвамында инвестиция проектын турыдан-туры гамәлгә ашыру өчен, ә аерым очракларда - Татарстан Республикасы Хөкүмәте карары буенча булдырылган яисә сатып алынган мөлкәткә расланган бизнес-план нигезендә проектның үзен аклау вакыты эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче өлешенә предприятиеләрнең мөлкәтенә га-

мәлдәге ставканың илле проценты күләмендә салым салына.

13 статья. Предприятиеләр һәм оешмалар табышына салым буенча өстенлекле ташламалар

Предприятиеләр һәм оешмалар табышына салым буенча өстенлекле ташламалар проект кысаларында төзелгән (сатып алынган) куәтләрдә яисә кертелгән технологияләр ярдәмендә җитештерелгән продукцияне (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сата башлаганнан соң беренче елда алынган табышка Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган өлешендә салым түләүдән тулысынча азат итүне күздә тота.

14 статья. Республика инвестиция программасына кертелгән инвестиция проектларын һәм максатчан программаларны гамәлгә ашыручы инвесторның ташламалы салым алу өчен документлар бирү тәртибе

Әлеге Закон нигезендә инвестор салым салуда өстенлекле ташламалар өчен инвестор теркәлгән урындагы салым органнарына проектны гамәлгә ашыруны башлау хакында язма рәвештә хәбәр итә, аңа түбәндәге документлар кушымта итеп бирелә:

Республика инвестиция программасына кертелгән проектлар исемлеген раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары күчермәләре;

Республика инвестиция программасына кертелгән проектны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр буенча аерым бухгалтер исәпләүләрен алып бару йөкләмәләре.

15 статья. Татарстан Республикасының республика инвестиция программасына кертелгән инвестиция проектларын (максатчан программаларны) гамәлгә ашыру өчен инвестиция кредитлары бирә торган кредит оешмаларына ташламалы салым салу

Республика инвестиция программасына кертелгән инвестиция проектларын (максатчан программаларны) гамәлгә ашыру өчен инвестиция кредитлары бирә торган кредит оешмаларына ташламалы

салым салу мондый кредитлар бирү нәтиҗәсендә алынган табышка предприятиеләрне һәм оешмаларны Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган өлешендә салымнан тулысынча азат итүне күздә тота.

Әлеге Закон нигезендә салым салуда ташламалар алу өчен кредит оешмасы үзе теркәлгән урындагы салым органнарына проектны кредитлый башлау турында хәбәр итә, аңа түбәндәге документлар кушымта итеп бирелә:

инвестиция кредиты бирү турындагы шартнамә;

Республика инвестиция программасына кертелгән проектлар исемлеген раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары күчермәсе;

Республика инвестиция программасына кертелгән проектны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр буенча аерым бухгалтер исәпләүләрен алып бару йөкләмәсе.

## V. Инвестиция эшчәнлеге субъектларының хокук гарантияләре һәм инвестицияләрне яклау

### 16 статья Инвестиция эшчәнлеге субъектлары хокукларының дәүләт гарантияләре

Дәүләт инвестиция эшчәнлеге субъектлары хокукларының тотрыклылыгын гарантияли. Инвестиция эшчәнлеге субъектларының закон чыгару актлары кабул ителгәнче төзелгән шартнамәләрдә (контрактларда) бирелгән хокукларын чикли торган нигезләмәләре булган закон чыгару актлары кабул ителгән очракта, бу шартнамәләрнең шартлары аның бөтен вакытына гамәлдә була.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, аларның урындагы затларының, законнарда каралган очраклардан гайре, инвесторларның инвестицияләү объектларын сайлау хокукларын чикләргә хаклары юк.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары һәм бу органнарның урындагы затлары законсыз гамәлләр кылган, шул исәптән әлеге органнарның законга туры килми торган актын бастырган очракларда инвестиция эшчәнлеге субъектларына килгән зыян тиешле бюджет исәбенә суд органнары карары нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

17 статья. Инвестицияләрне яклау

Дәүләт законнар нигезендә инвестицияләрне, милек рәвешләренә карамастан, яклауны гарантияли. Инвесторларга инвестицияләр белән идарә итүгә һәм эш итүгә киртә булырдай дискриминация характерындагы чаралар куллануга юл куймый торган тигез хокуклы эшчәнлек шартлары тәэмин ителә.

Татарстан Республикасында инвестицияләр, законнарда каралган очраклардан һәм тәртиптән тыш, национализацияләнергә тиеш түгел, реквизицияләнә яисә конфискацияләнә алмыйлар.

Инвесторлар тарафыннан кертелгән яисә сатып алынган максатчан банк кертемнәре, акцияләр яки башка кыйммәтле кәгазьләр, алынган мөлкәт өчен түләүләр, шулай ук аренда хокуклары, законнар нигезендә тартып алынган очракларда инвесторларга кире кайтарып бирелә, моңа инвесторларның үзләре яки алар катнашында кылган гамәлләре аркасында файдаланылган яисә юкка чыгарылган суммалар керми.

Инвестицияләр иминләштерелә алалар, ә законнарда турыдан-туры каралган очракларда иминләштерелергә тиешләр.

18 статья. Инвестиция эшчәнлеге субъектларының җаваплылыгы

Инвестиция эшчәнлеге субъектлары тарафыннан, чит илләрнеке дә кертеп, законнарның таләпләре, шартнамәләрдә (контрактларда) үзара каралган йөкләмәләрнең таләпләре үтәлмәгәндә, әлеге субъектлар билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

Барлык дәрәҗәдәге дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары дәүләт заказларын, инвестиция проектларын һәм программаларын гамәлгә ашырганда төзелгән шартнамәләрдә (контрактларда) һәм килешүләрдә каралган йөкләмәләре өчен мөлкәт җаваплылыгына ия булалар.

19 статья. Әлеге Законны куллануга бәйле рәвештә килеп чыгучы бәхәсләрне хәл итү

Әлеге Законны куллануга бәйле рәвештә килеп чыгучы бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителәләр.

20 статья. Инвестиция эшчәнлеген туктату яисә туктатып тору

Инвестиция эшчәнлеген туктату яисә туктатып тору законнарда, шулай ук шартнамәдә (контрактта) каралган тәртиптә башкарыла. Инвесторлар үзара шартнамәләр (контрактлар) буенча үзләренең йөкләмәләрен үтәүне туктату аркасында инвестиция эшчәнлегендә башка катнашучыларга килгән зыянны, шул исәптән керми калган файданы да түлиләр.

## VI. Йомгаклау нигезләмәсе

21 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президент

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 25 ноябре
N1872